وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

**Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!**

# Дин вә Мәгыйшәт

№14 (131). 6 апрель 2012 / 15-җөмәдел-әүвәл-1433

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ



**Мәдрәсәләрдән "робот"лар чыгармыйк!** ▷2◁



**Ш.МӘРҖАНИ образы әдәбиятта һәм сәнгатьтә** ▷2◁



**Илһам хәзрәт кайтарган илһам** ▷3◁

## ЯҢАЛЫКЛАР

### АРЧАДА – ӨЧ АТНАЛЫК СЕМИНАР

Арча районы мөхтәсибәте мөслимә укытучылар өчен оештырылган өч атналык семинар башлап җибәрде. Ул районның "Өмет" тернәкләндерү үзәге базасында уза. Арча районы имам-мөхтәсибе Раил хәзрәт Гыйләҗев хәбәр иткәнчә, семинар вакытында мөслимәләр яңа күнекмәләр үзләштерә һәм тәҗрибә уртаклаша алачак.

### КОЛ ШӘРИФ МӘЧЕТЕНДӘГЕ БӨТЕН ДИНИ ЭШЧӘНЛЕК МӨФТИЯТ КАРАМАГЫНА БИРЕЛӘ

"Казан Кремле" дәүләт тарихи-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы, ТР мөселманнары Диния нәзарәте һәм "Казан Кремле" фонды арасында Кол Шәриф мәчетеннән уртак файдалану турында килешү төзелде. Килешүдә мәчет бинасыннан файдалануда бу якларның вәкаләтләре билгеләнгән. Кол Шәриф мәчетендәге бөтен дини эшчәнлек ТР мөселманнары Диния нәзарәте карамагына бирелә.

### ӘЛМӘТ МӨХТӘСИБӘТЕ ХӘЙРИЯ ЯРДӘМЕ КҮРСӘТТЕ

Әлмәт шәһәре мәчетенә йөрүчеләр Әлмәт муниципаль районы имам-мөхтәсибе Рафикъ хәзрәт Миңнәхмәтов җитәкчелегендә Анжела Вавилова исемендәге Фондка акчалата хәйрия ярдәме күчерде.

Исегезгә төшерәбез: Вавиловлар гаиләсендәге Анжела исемле кызга 2 яшь тә 10 айлык чакта табиблар "острый лимфобластный лейкоз" дигән диагноз куя. Шул вакыттан Анжеланың әти-әнисе үз баласының тормышы өчен көрәшә башлый. Әмма 2003 елның 6 февралендә кыз вафат була. Онкологик авыру балаларның һәм аларның әти-әниләренең барлык хәсрәтләрен аңлаган хәлдә, бала борчуын баштан кичергән Вавиловлар гаиләсе шул ук көнне акканлылык (лейкемия) белән интегүче балалар өчен ярдәм фонды төзергә һәм аны үзләренең кызлары исеме белән атарга карар кыла. Мәрхәмәтле кешеләр ярдәме белән кызларын дәвалау өчен Анжеланың әти-әнисе җыярга өлгергән барлык акчалар да Фондның Устав капиталы нигезенә салына.

Татарстан мөфтие Илдус хәзрәт Фәиз узган елның ноябрендә ТР мөселманнары Диния нәзарәте, Казан Епархиясе һәм ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы арасындагы хезмәттәшлек турындагы өч яклы килешүне имзалау мәсьәләләрен уртага салып сөйләшү өчен Фонд рәисе Владимир Владимирович Вавилов һәм ТР Сәламәтлек саклау министры Айрат Зәки улы Фәррахов белән очрашкан иде. Бүгенге көндә ТР мөселманнары Диния нәзарәте Казандагы 4 нче балалар терапевтия санаториясе базасында ачылган хосписның күзәтчелек советына керә һәм әлеге Фондка ярдәм күрсәтүен дәвам итәрә.

### ГАЗЕТАЛАРГА ЯЗЫЛЫРГА ОНЫТМЫЙК!

1 апрельдән алып 28 июньгә кадәр **2012 елның II яртыеллыгы** өчен "Дин вә мәгыйшәт" (язылу индексы - 16046) һәм "Умма" (83072) газеталарына язылырга мөмкин. 6 айга язылу бәясе - **118,38 сум**.

# Ана күңеле баладамы?

**Президент каршындагы бала хокуклары буенча вәкил Павел Астахов сүзләренә караганда, 2011 елны Россиядә меңнән артык бала үтерелгән, шуларның өчтән бере (!) үз әти-әниләре тарафыннан. Экспертлар фикеренчә, соңгы елларда ата-аналарның үз балаларын үтерүләре гадәти хәлгә әверелеп бара.**

Хәтта әхлакны, динне, милләтне саклаучы дигән исем алган татар авылларында да мондый явызлыклар эшләнә. Нәрсә бу, кем гаепле һәм ни кылырга? Яңалыкларның беренче юлларында булган Брянск вакыйгасы бар Россия халкын киеренкелектә тотты дисәк тә арттыру булмас, мөгаен. Саклауга һәм яклауга мохтаҗ, күңелендә бер әшәкелек булмаган нарасый олылар тарафыннан үтерелә. Мондый вәхшилекне без хәтта хайваннар дөньясында да очрата алмыйбыз. Космосны буйсындырырга керешкән адәм балалары әле һаман да җаһилият дәвереннән ерак китмәгән дигән нәтиҗә генә ясыйсы кала. Ни кызганыч, моңа охшаш хәбәрләрне без еш ишетергә мәҗбүрбез.

Бер уйласак, җәмгыять яшь буынны тәрбияләүдә үзендә булган барлык гадел һәм мәрхәмәтле юлларны кулланырга тиеш. Бала бу дөньяга зәгыйфь булып туа, ул махсус ярдәмгә һәм тәрбиягә мохтаҗ. Һәрбер ил балаларны яклап төрле кануннар, проектлар кабул итә, хәтта елның бер көне "Балаларны яклау көне" дип игълан ителгән. Әмма боларның гына аз икәнлегенә без көннән-көн ныграк инанабыз. Тормышка кагылышлы иң нечкә мәсьәләләрне үз эченә алган ислам динендә инде VI гасырда ук бала хокуклары хакында кануннар кабул ителгән. Алар иң беренче чиратта Аллаһы Тәгалә куйган канун булулары белән аерылып тора, гаделлекләре хакында бернинди бәхәскә дә урын кала алмый. Ислам дине бала хокуклары хакында ниләр әйткәнен белү өчен Коръәнгә һәм хәдисләргә күз салыйк.

Ислам дине балага иҗтимагый һәм хокукый гарантияләр бирә, чөнки бала ул безнең киләчәгебез, Аллаһы Тәгаләнең бүләге. "Мал һәм балалар дөнья тереклегенең зиннәтләредер", - дип әйтелә Коръәндә (18:46).

Баланың иң зур хокукларының берсе булып, яшәү хокукы тора. Бар нәрсәгә дә гомерне Аллаһы Тәгалә бирә, берәүнең дә ул гомерне өзәргә хакы юк, хәтта ата-ананың да. Ислам, кеше гомерен, бала бу дөньяга килгәнче үк, саклауны бурыч итеп куя: "Фәкыйрь булудан куркып, балаларыгызны үтермәгез! Балаларыгызны да, үзегезне дә Без ризыкландырырбыз, әлбәттә, үз балаларын үтерүләре гафу ителми торган хатадыр, зур гөнаһдыр" (17:31). Беребезнең дә энҗе-мәрҗәннәрне яки алтыннарын белә торып суга салганнарын күргәнебез юк, әмма тормышы бәһасез булган кешене үтерү, аборт ясату гадәти хәлгә әверелеп бара.

Тәрбия һәм тәэмин итү хокукы:

Бала бу якты дөньяга килә, әмма ул әлегә үзен яклый һәм саклый алмый, бу вазифаларны ата-ана үз өстенә алырга тиеш. Ата баланы матди яктан тәэмин итәргә бурычлы булса, әнинең бурычы балага яхшы тәрбия бирү, хатын-кызга гаиләне акча ягыннан тәэмин итү вазифасы куелмаган, әмма ата кеше бала тәрбиясендә катнашырга тиеш, бигрәк тә ир-егетләр тәрбияләгәндә. Бала тәрбиясендә йомшаклык, мәрхәмәтлелек, гаделлек сыйфатларын куллану мәҗбүри. Әгәр бар эшләрдә дә безгә үрнәк булырлык пәйгамбәребезнең (сгв) тормышына күз салсак, аның беркайчан да балаларга тавыш күтәргәнен күрмәбез. Балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып, ул һәрвакыт алар белән шаярган, уйнаган, көлгән, аларны борчыган сорауларга аңлаешлы итеп җавап биргән. Соңгы елларда зур үсеш алган психология фәне дә пәйгамбәребез (сгв) кулланган ысулларны һәрьяклап куәтли.

Бервакыт бер төркем сәхабәләр, пәйгамбәребезнең (сгв) балаларны үпкәнен күреп, сораганнар: "Син аларны үбәсеңме?" Пәйгамбәребезнең (сгв) җавабы уңай булган. Шунда сахәбәләр: "Без бит балаларыбызны үпмибез", - дигәннәр. Пәйгамбәребез (сгв): "Әгәр Аллаһ сезнең йөрәгегездән мәрхәмәтлелекне алган икән, мин нәрсә эшләтим соң?" - дип җавап кайтарган.

***Үзәкләшкән дини оешма - ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Илдус хәзрәт ФӘИЗ***

# *Зирәклек патшалыгы*

**Идел Болгарстанында ислам дине 922 елның 21 маенда - болгар патшасы Алмыш тарафыннан чакырылган Багдад илчелеге килгәч, рәсми рәвештә кабул ителә. Моннан берничә ел элек Татарстан Дәүләт Советы, киң җәмәгатьчелекнең теләген искә алып, 21 майны истәлекле көн буларак һәр елны билгеләп үтү турында карар кабул итте.**

Югары үсеш алган ислам мәдәнияте бүгенге тормышыбызның әхлакый нигезен тәшкил итә.

Болгарлар элек-электән мәдәниятле халык булган, тыныч хезмәт белән шөгыльләнгән: иген иккән, мал-туар асраган, шәһәрләр торгызган, күрше халыкларга, ерак илләргә сугыш белән түгел, сәүдә эшләре белән барган. Мәшһүр рус тарихчысы С.М.Соловьёв аларны "сәүдә һәм сәнәгать халкы" дип атап, болай дип язып калдырган: "Издавна, когда ещё русский славянин не начинал строить на Оке церквей христианских, не занимал ещё этих мест во имя европейской гражданственности, болгарин слушал уже Коран на берегах Волги и Камы..."

Ислам дине кабул ителгәч, борынгы рун-төрки язмалар гарәп графикасына алмашына. Болгар иленең шушы шартларда гарәп язуына күчүе кулайрак булган, чөнки ул болгар фәне һәм мәдәниятен халыкара дәрәҗәгә күтәрү өчен яңа мөмкинлекләр ачкан. Эзлекле рәвештә гарәп теле болгар теле белән бергә фән һәм дипломатик теленә, ә фарсы теле, төрки (болгар) теле белән беррәттән, поэзия теленә әверелә.

Шәрык илләре белән сәүдә һәм икътисади элемтәләр көчәю болгар мәгарифе системасы оешуга китерә. Х гасыр башында гарәп сәяхәтчесе, язучы һәм географ Ибне Рөстә язмаларына караганда, "аларның (болгарларның. - М.И.) күпчелеге ислам динен тота һәм аларның авылларында мөәзин һәм имамнар белән мәктәпләр һәм мәчетләр эшли". Бу сүзләр археологик материаллар белән дә раслана: болгар калаларын казыганда табылган язу әсбаплары (каләмнәр, кара савытлары), таштан, сөяктән һәм бакырдан ясалган әйберләргә язылган аерым сүзләр, кыска гына җөмләләр шул язмачылыкның гади һөнәрчеләр арасында да киң таралганлыгын күрсәтә.

*(Ахыры 3 нче биттә.)*



# Мәдрәсәләрдән "робот"лар чыгармыйк!

**Шәкертлек еллары белем эстәүчеләрнең күңелендә, йөрәгендә онытылмаслык эз калдыра. Кайсы гына галимне яисә шәехне алсак та, алар үзләренең тормыш юлын шәкерт булып белем алудан башлаган. Юкка гына без яңа гына мәктәп-мәдрәсә ишекләрен ачып кергән укучыларга пәйгамбәребезнең Мөхәммәд (сгв) хәдисен җиткермибез: "Бишектән алып ләхеткәчә гыйлем ал".**



"Шәкерт" дигәндә без белем алучы кешене күз алдында тотабыз. Әйе, иман китергән кешеләр өчен "гыйлем" дигәч, иң беренче чиратта Аллаһны тануны, дин белемнәрен өйрәнүне, шәригать кануннарын үзләштерүне аңлыйбыз. Аллаһы Тәгалә - Үзе шушы белемнәрне бирүче һәм алучы. Коръәни-Кәримдә Аллаһы Тәгалә болай ди: "Фәрештәләр әйттеләр: "Ий һәр кимчелектән пакь булган Раббыбыз! Бездә һич белем юк, мәгәр Син белдергәнне генә беләбез. Син, әлбәттә, һәрнәрсәне белүче, хикмәт белән эш кылучысың" ("әл-Бәкара (Сыер)" сүрәсе, 32 нче аять).

Аллаһ дөньяга белемне үзенең Китаплары - Тәүрат, Зәбур, Инҗил һәм Коръән аша иңдерде. Мөселман галимнәре дөньяга алгебра, химия, география фәннәрен бүләк итте, тыйб (медицина) фәне үсешендә дә катнашты. Бөтен дөньяга танылган галимнәрдән Әлбайруни, Хаварезми, Әбугалисина, ибне Бутута, Әхмәд ибне Фадланнарның исемнәрен атый алабыз. Без санаган әлеге галимнәр әүвәл Коръән, хәдис, шәригать белемнәрен өйрәнеп, дөньяви фәннәрдә ачышлар ясаган. Дин гыйлемен өйрәнү аеруча бөек, дәрәҗәле, абруйлы гамәлләрдән санала. Әмма безнең көннәрдә татар милләте дин гыйлемен өйрәнергә ашкынып торуы белән мактана алмый. Һәм бу бик тә аяныч, чөнки дин гыйлемен өйрәнмәгән, дин галимнәре тәрбияләмәгән милләтнең киләчәге булырмы? Дин гыйлемен үзләштерү бик тә катлаулы, чөнки ул кешенең рухи халәтенә бәйле. Мөселман милләттәшләребез бу гыйлемне йөрәктән йөрәккә, җаннан җанга тапшырып килде, дин гыйлемен ниндидер бер дөньяви фәнгә әйләндереп калдыру яки әйләндерергә тырышуның бик зур хата икәнлеген аңлап яшәде.

Коръән укыганда Аллаһның рухи көче безгә тәэсир итүне сизмәсәк, шәкертләребез шуны аңламаса һәм тәэсирләнмәсә, без үзебезнең теләгән максатыбызга ирешә алмаячакбыз. Хәдисләрдә пәйгамбәребезнең (сгв) рухи халәтен тоймасак, Сөннәтне аңлау дәрәҗәсе бик түбән булыр. Моны аңлар өчен пәйгамбәребезнең (сгв) мәчет-мәдрәсәсе турында укып, фикер йөртергә һәм аннан файда алырга өндәү кирәк.

Кемнәр соң алар пәйгамбәребезнең шәкертләре? Мәккәдә вакытта пәйгамбәребез (сгв) үзенең беренче шәкертләре белән бу дөньяны коллыктан азат итте, җаһиллек караңгылыгыннан иман нурына алып чыкты. Мәдинә шәһәрендә пәйгамбәребез (сгв) мәчетенең бер ягы кыйбла ителеп Иерусалимга карап торган һәм төзелеп бетмәгән була, аңа пәйгамбәребез (сгв) түшәм куярга боера. Шуның астына мескеннәр, яңа гына һиҗрәт кылган сәхабәләр җыелган. Алар шулкадәр фәкыйрь булганнар ки, хәтта сарык йонынннан иләнгән каты киемнәрдән йөргәннәр. Болар - Бәдер сугышыннан соңгы мөһаҗирләр. Алар пәйгамбәребездән (сгв) дәрес ала: Коръән ятлыйлар, укырга-язарга өйрәнәләр. Бу шәкертләрнең иң күренеклеләре Әбу Һүрайра, Әбу Зәрил Гаффәри, Сәлман Фариси була.

Мәдинәдә пәйгамбәребез (сгв) мәдрәсәсеннән 51 сәхабә-шәкерт гыйлем алып, Аллаһның динен, пәйгамбәребезнең (сгв) сөннәтен бөтен дөньяга тарата. Коръәнне ятлап, шәригатьне пәйгамбәребезнең (сгв) үзеннән өйрәнеп гамәлгә ашыручылардан булалар. Гыйлем аларның калебләренә үтеп кереп, аларның үз-үзләрен тотуда чагылыш таба.

Рәсүлебез (сгв) әйтте: "Аллаһ кемгә булса да яхшысын, хәерлесен теләсә, ул аңа динен аңлавын бирер".

Бүгенге мәдрәсә тәмамлап чыккан шәкертләрнең бик азы гына үзләрен дин тарату, гыйлем бирү эшенә багышлый. Әйе, алар яңадан-яңа технологияләр кулланырга сәләтле, зиһеннәре яхшы, араларында Коръәнне яттан белүчеләр дә бар. Әмма Коръән, хәдистән генә дәлилләр китереп, факихларның иҗтиһадын инкарь итүчеләр дә юк түгел. Ни генә дисәк тә, безнең калебләребезне дөнья мәшәкатьләре чорнап алган, рухиятебез ярлы, матди яктан дөнья ярышында барабыз, шул исәптән шәкертләребез дә калышмаска тырыша. Мәчетләребездә сарык тиресе кигән бүреләр хәтсез күренә. Йөрәкләребез чирле, авыру. Күңелләребез пакьләнми торып, сәламәт йөрәк һәм тән, имин җәмгыять булмаячагы көн кебек ачык. Аллаһтан куркып кына гыйбадәт кылу дөрес булмас. Рәсүлебез (сгв) Мәдинә шәһәрендә үзенең беренче хөтбәсендә болай диде: "Аллаһны яраткан кешене яратыгыз, Аллаһны бөтен йөрәгегез белән яратыгыз, Аллаһның сүзеннән аерылмагыз, аны зикер итүдән туктамагыз. Хакыйкый курку белән курыксагыз, Аны зикер иткәннән калебләрегез, йөрәкләрегез кырысланмас, катыланмас". Аллаһны ярата белсәк кенә гыйбадәтебез, кылган гамәлләребез дөресләнер. Шәкертләребез шәригать фәннәре укып, аны йөрәк аша үткәрмәсәләр, Аллаһны сөя белмәсәләр, йөрәкләрен зикерләр әйтеп пакьләндермәсәләр, мәдрәсәдән бары тик каты бәгырьле шәхесләрнең, матди якны гына кайгыртучыларның яисә "робот"ларның гына чыгачагы көн кебек ачык.

Иң мөһиме - беренче көннәрдән үк шәкертләргә дөрес юнәлеш биреп, аларны тирән фикер йөртергә төшендереп, бәхәсләрне хикмәт белән чишә белергә, зиһенен уйларга күнектерергә, фәннәрне үзләштерү ысулларына өйрәтүне алгы планга куярга кирәк. Бу - безнең алда торган зур бурыч. Шулай ук астрономия, физика, биология, алгебра кебек фәннәрдән дә белемнәре булу мөһимдер. Бу фәннәр белән таныш булмасалар, күкне, космосны мәхлук итеп танымаслар, вакыт-урын мәсьәләләрен аңламаслар, гакыйдә, фикъһе, мирас фәннәренә төшенергә бик авыр булып, дөрес булмаган ышанулар, игътикадлар килеп чыкканлыгын ишетеп-белеп торабыз.

Мин мәдрәсәдә укый башлагач, бабамнан калган китапларны карый башладым. Бабам - заманында мәдрәсә бетереп, дин гыйлеме алган кешеләрнең берсе иде. XX йөз башында чыккан китап нинди бүлекләрдән торган соң? 1 нче бүлек - "Пәйгамбәребезнең тормышы"; 2 нче бүлек - "Гакыйдә"; 3 нче бүлек - "Фикъһе" (ул үзе өч өлешкә бүленгән - гаилә мәсьәләләре, гыйбадәт һәм мөгамәлә); 4 нче бүлек - "Хәлифләрнең тормыш юлы". Китап бик аңлаешлы һәм кыска телдә язылып, иң кирәкле мәсьәләләрне чагылдырган. Ә бүгенге көндә нәрсә? Хәзерге мәдрәсә шәкертләре гакыйдә фәненнән һәм гарәп теленнән башканы мөһим дип санамый. Фикъһе дәресе алдыннан III курс шәкертеннән намаз шартларын, рөкеннәрен, вәҗебләрен сораган идем, 13 шәкертнең берсе генә дөрес, тулы җавап бирә алды (сату-алу, риба мәсьәләләре турында сөйләп тә торасы юк инде).

Тәфсир фәненә килгәндә исә бу фәнне сарыф (морфология), нәхү (грамматика), бәлага (риторика) фәннәрен өйрәтмичә, тирәнтен аңлатып булмаячак. Гарәп телен укытканда хәтта 1917 елгы революциягә кадәр гаруз (шигъри үлчәм) дәресләре дә кертелгән. Шул сәбәпле татар мәдрәсәләреннән әдипләр, шагыйрьләр үсеп чыга алган. Татар мәдрәсәләреннән хәтта дипломатлар да тәрбияләнеп чыга. Мондый күренеш-нәтиҗәләр мәдрәсәләребездә яхшы остазларның хезмәт куюы турында сөйли дә инде.

**Рафикъ хәзрәт ИСЛАМГАЛИЕВ,**
**Түбән Каманың "Рисәлә" мәдрәсәсе мөдире**

# БӘЙРӘМ КЕБЕК БӘЙГЕ



**31 март көнне Кукмарада намаз укучылар бәйгесе үткәрелде. Моңа кадәрге унике елда Коръән укучылар бәйгесе буларак үтә торган чараны быел беренче мәртәбә намаз уку ярышы итеп уздырдылар.**

Кукмара мөхтәсибәтеннән алынган мәгълүматларга караганда, бәйгедә олысы да, кечесе дә - барлыгы 148 кеше катнашкан. Аларның һәммәсе дә 2 рикагать намаз укып күрсәткән. Катнашучыларны 5 номинация буенча бәяләгәннәр:

1. ***Намаз уку әдәбе.***
2. ***Киенү рәвеше.***
3. ***Кыйраәт.***
4. ***Намаздагы дога-зикерләрнең укылышы.***
5. ***Көндәлек намазларны башкару.***

Барлык катнашучылар яшенә, яттан белгән сүрәләрнең санына карап, биш төркемгә бүленгән: 7 яшькә кадәрге балалар, 8-12 яшьлекләр, 13-17 яшьлек яшүсмерләр, 18 яшьлекләр һәм аннан өлкәнрәкләр. Коръәннең ахыргы 22 сүрәсен ("әд-Духә" - "ән-Нәс") яттан белүчеләр өчен өстәмә төркем булдырылган (әлбәттә инде, ир-егетләр һәм хатын-кызлар аерым ярышкан).

Иң сөенечлесе - 7 яшькә кадәргеләр төркемендә 27 сабыйның катнашуы. Аларның күпчелеге 2 рикәгать намаз укып күрсәтә ала икән, димәк, мөселман гаиләләрендә тәрбия, белем бирү эше өзлексез барганлыкның күрсәткече бу.

Һәр төркемдә I урын бер генә кешегә бирелсә, II урынга - 2, III урынга - 3 кеше ия булган. Призлы урыннарга лаек булучыларга иганәчеләр ярдәмендә әзерләнгән затлы бүләкләр тапшырылган. Моннан тыш, һәр катнашкан балага күчтәнәчләр пакеты, ә олыларга китап белән бер кап чәй өләшенгән. Шулай итеп, бәйге матур бер бәйрәм төсе алган. Катнашучылар да, карарга килүчеләр һәм оештыручылар да бик канәгать калган. "Әлбәттә, иң мөһиме - Аллаһ Раббыбызның бездән канәгать, разый булуы. Киләсе елда да мондый бәйге үткәрергә исәпләп торабыз, Аллаһ Үзе ярдәмче булсын", - диләр Кукмарада яшәүче мөселман кардәшләребез. Аларның изге теләк-ниятләре тормышка ашса иде. Әмин.

**Фаил Зәйнуллин фотосы**

# Балалар көч сынашты

**Балык бистәсе районының Җәмигъ мәчетендә әхлак дәресләрендә актив катнашкан, ислам дине нигезләрен яратып өйрәнүче балалар арасында бәйге үтте. Беренче тапкыр үткән мондый чарада йөздән артык укучы катнашты, дип хәбәр итә "Авыл офыклары" газетасы.**

Район имам-мөхтәсибе Сәүдәхан хәзрәт Гайнетдинов балаларның болай актив булуларына ихлас күңелдән сөенүен җиткерде. Шуннан соң район мәгариф бүлеге башлыгы Илсур Садыйков сүз алды. Ул соңгы елларда укучы балаларның әдәпле, тәртипле булып үсүләренә шатлануын әйтте. Ә монда инде аларга дини тәрбия бирүнең әһәмияте зур булуын белдерде.

Балалар, чыннан да, актив булып чыкты. Һәрбер чыгыш ясаучы үзенең яхшы әзерлекле булуын күрсәтте. Догалар уку буенча Балык бистәсеннән Мөслим Фәсхетдинов, Котлы Бөкәштән Гүзәл Яруллина макталды. Азан әйтү бәйгесендә Күгәрченнән Булат Мөхәммәтҗанов җиңү яулады. Ә Коръән уку бәйгесендә Зилә Фәсхетдинова - беренче, Чыршылы Елгадан Рәзилә Сафина белән Балык бистәсеннән Алинә Бәширова икенче урынга ия булды. Ә "Намаз" номинациясендә Күкидән Гөлүсә Заһидуллина белән Айсылу Нәбиуллина җиңүче булды. Малайлар арасында намаз уку бәйгесендә Иске Арыштан Илсаф Гыйльметдинов белән Рәсим Кәримовка тиңнәр булмады. Барлык җиңүчеләргә бүләкләр тапшырылды.

***Роза ИСМӘГЫЙЛОВА***

# Ш.МӘРҖАНИ ОБРАЗЫ ӘДӘБИЯТТА ҺӘМ СӘНГАТЬТӘ

**(Ахыры. Башы газетабызның 30 март (№13) санында.)**

Ш.Мәрҗани образы театр, рәсем сәнгатендә, бюстлар иҗат итүдә билгеле дәрәҗәдә чагылыш тапты һәм таба килә. XX гасырның утызынчы-кырыгынчы елларында театр сәнгате өлкәсендә тарихи эчтәлекле "Тукай" (Ә.Фәйзи, 1939), "Идегәй" (Н.Исәнбәт, 1941), "Каюм Насыйри" (М.Гали һәм Х.Уразиков, 1945) әсәрләре буенча Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында спектакльләр кую юлга салына. Өйрәнелүче тема күзлегеннән караганда, мәшһүр мәгърифәтче К.Насыйриның 120 еллыгына багышлап иҗат ителгән һәм сәхнәдә куелган "Каюм Насыйри" пьесасы игътибарга аеруча лаеклы. Татар халкының ике данлы шәхесе - К.Насыйри һәм Ш.Мәрҗани образларын сәхнәгә күтәрү ягыннан бу спектакль татар театрында аеруча әһәмиятле урын алып тора.

Совет хөкүмәтенең баштагы чорында шактый вакыт дәвамында Ш.Мәрҗани буржуаз галим, дини реформатор буларак кына бәяләнеп киленде, аның тормышы һәм гыйльми эшчәнлегенә багышланган махсус фәнни тикшеренүләр, эзләнүләр алып барылмады. Менә шушы дәвердә Г.Камал театрында режиссёр Хөсәен Уразиков куйган спектакль берничә дистә елга сузылган фәнни фикерләүдәге бушлыкны берникадәр булса да тутырырга булышучы кыйммәтле хәзинә булды.

Бер үк чорда, бер үк тарихи шартларда яшәгән К.Насыйри һәм Ш.Мәрҗани, эш гамәлләрен төрле юнәлештә баркарсалар да, туган халкына тугры хезмәт иттеләр. Спектакльне карау дәвамында тамашачы танылган мәгърифәтче, мәшһүр тарихчы турында шактый киң мәгълүмат ала иде.

Спектакльдә катнашучы барлык персонажларның образлары, нигездә, Казанга мөфти Сәлимгәрәй Тәфкилев килү вакыйгасы белән бәйле рәвештә яктыртыла, ачыклана. Дин әһелләре, шәһәр байлары, сәүдәгәрләре морза белән очрашуны зур вакыйга буларак кабул итсәләр дә, бу тантанада ике зур шәхес - К.Насыйри һәм Ш.Мәрҗани катнашмыйлар. Сәбәбе шул: университетның Археология, тарих һәм этнография җәмгыятендә ясалачак К.Насыйри докладын тыңлауны, бәяләүне үзләренә мөһимрәк гамәл дип санау. Мөфтине каршылаганда ике танылган затның катнашмавы дин әһелләре һәм мөфтинең аларга булган ачуын кабарта. "Гаеп"ләрен танудан баш тарткан затлар җитди җәзага тартыла: К.Насыйри яшәгән йортыннан куып чыгарыла, Ш.Мәрҗани исә мөдәррислек исеменнән мәхрүм ителә. Аның муллалык указы алына. Спектакльнең сюжетында Насыйри төп герой, ә Мәрҗани исә Насыйриның якын фикердәше, көрәштәше буларак кына гәүдәләнә. Тамашачы мәшһүр тарихчысы белән спектакльнең өченче пәрдәсендә очраша.


Ш.Мәрҗани мөфти белән булган бәхәс вакытында түбәндәге фикерләрен әйтте: "Минем теләгем бер генә - шәкертләремне мәгърифәтле ясау, төрле хорафаттан миләрен арчу. Дөньяны таныту. Дөньяда яшәргә сәләхиятле итү. Минем мәдрәсәмне хәтме көтеб (укып бетереп) калган шәкертләр, мәдрәсәдән чыккач, үзләренә теләсә нинди исем таксыннар, ул ягына мин кагылмыйм, ләкин миннән чыккан шәкертләр, менә болар кебек, фидия (йолым) козгыннары булып кала торган булсалар, бөтен һөнәрләре үлек күмү, үлек юу, мәҗлестән мәҗлескә йөреп ашау булса, бөтен белемнәре башкаларны көферлектә гаепләп, гайбәт сөйләүдән артмый торган булса, мин андый шәкертләрне мәдрәсәмдә асрамыйм да, укытмыйм да".

Бу монологта Мәрҗанинең педагогика өлкәсендәге карашлары шактый ачык чагылдырылган. Ул шәкертләренең аңлы, фикерләргә сәләтле, тирән белемле, тәрбияле кешеләр булып үсүләренә ирешергә омтыла. Диннең катып калган догма булмыйча, реаль тормыш өчен файдалы, саф һәм пакь тәгълимат булуын тели, шәкертләрен дә шундый рухта формалаштыру юлларын эзли.

Спектакльдә Ш.Мәрҗани образын режиссёр Шириаздан Сарымсаков һәм артист Мәҗит Илдар тудыра. Тамашачы нык гәүдәле, горур, үз дәрәҗәсен тирән аңлап эш итүче, традицион чалма-чапан, итек-кәвеш кигән, тышкы кыяфәте үк зыялы зат булуын раслаучы шәхесне яратып кабул итә. Спектакльдә катнашкан күренекле рус галимәсе Ольга Фёдоровна (М.Миңлебаева, Г.Шәрипова) белән фән проблемалары турында барган сөйләшү, мөфти Сәлимгәрәй Тәфкилев (Т.Гыйззәт) һәм аның иярченнәре белән булган бәрелеш күренешләре мәшһүр галимгә хас булган шәхси сыйфатларны, башка кешеләргә булган игътибарлы мөнәсәбәтен, белем дәрәҗәсен шактый тулы ачыклыйлар. Ольга Фёдоровна белән фикер алышу барышында галимнең үз-үзен тоту манерасы, сөйләшү, аралашу осталыгы, зирәк, мөлаем шәхес булуын тою авыр түгел. Профессор Смирнов (Х.Сәлимҗанов) кабинетында барган икенче эпизодта Мәрҗанинең тирән фикер йөртүче, төпле белемле тарихчы галим булуы янә ачыклана. Мөфти һәм аның иярченнәре белән булган бәрелеш процессы Шиһаб хәзрәтнең сабыр табигатьле, үз сүзендә нык тора алучы зат булуын күрсәтә. Мөфти кулыннан килгән барлык чаралар белән Мәрҗанине үзенә буйсындырырга, баш идерергә, гафу үтенергә мәҗбүр итәргә тели. Әмма үз максатына ирешә алмый. Муллалык указыннан мәхрүм ителү дә галимнең горур характерын сындыра алмый. Мәрҗани башын югары тоткан хәлдә сәхнәдән җиңүче буларак чыгып китә. Бу күренешне күзәткән тамашачының көчле алкышы данлы улына туган халкының тирән рәхмәте булуы, олы мәхәббәте турында сөйли.

Театр белгече Мөхәммәтгали Арсланов бу спектакльнең вакытында киң җәмәгатьчелек тарафыннан мәдәният дөньясында әһәмиятле зур вакыйга буларак кабул ителүе турында бәян итә. Спектакльгә рецензия язган театр, әдәбият белгечләре Латыйф Җәләй, Гази Кашшаф бу тамашага югары бәя биреләр, Ш.Мәрҗани образының ничек иҗат ителүенә дә киң тукталалар. "Мәрҗанинең үзенә лаеклы характеры табылган. Мәрҗани безнең алга үз юлында нык торучы, нинди генә киртәләр булса да туктамый баручы көчле галим булып килеп баса. Илдар белән Сарымсаков иптәшләр бу образның чын йөзен ачу өстендә күп эшләгәннәр һәм шул образда аларның талант байлыкларының бизмәне дә сизелә", - дип язды Л.Җәләй. Г.Кашшаф исә түбәндәге гыйбарәләре белән телче һәм әдәбиятчы галимнең фикерләрен куәтли: "Әдәбиятта беренче тапкыр буларак, галим һәм мулла тибы буларак бирелгән Мәрҗани сурәте драмада хаклы рәвештә отышлы урын алган. Ул - игътибарга лаеклы һәм фикер уята торган тип", - ди "Тарихи шәхесләрне гәүдәләндерү юлында" исемле бәяләмәсендә.

Алга таба Нәкый Исәнбәтнең "Мулланур Вахитов", "Муса Җәлил", "Гөлҗамал" кебек тарихи пьесаларны сәхнәләштереп (1948, 1956, 1968) шактый тәҗрибә туплаган Г.Камал исемендәге театр "Каюм Насыйри" әсәренә 1969 елда янә мөрәҗәгать итә. Бу юлы Ш.Мәрҗани образын танылган артист Фатих Колбарисов иҗат итә. Ул галим образын тудырганда аның фаш итүче, көрәшче сыйфатларын калкурак итеп ачарга омтыла. Бу спектакльгә театр белгече Азат Әхмәдуллин нигездә уңай бәя бирсә дә, спектакль бу юлы озын гомерле була алмый.




**Ш.Мәрҗани кабере**

М.Арсланов бик хаклы: "Бүген Ш.Мәрҗани тормышы, эшчәнлеге, калдырган мирасы яңа чор таләпләреннән, мөмкинлекләреннән чыгып тикшерелергә, өйрәнелергә лаеклы... Мәрҗанинең үзенә генә багышланган, аның гаҗәеп күпкырлы образын тулысынча иңләгән сәхнә әсәре булдыру да, ниһаять, көн тәртибенә куелырга тиеш".

Мөхтәрәм галимнең бу кыйммәтле фикерләре язучылар, рәссамнар, композиторлар берлекләре җитәкчеләрен, зыялы затларны җитди уйландырсын иде. Махсус рәвештә Ш.Мәрҗанигә багышлап иҗат ителгән зур күләмле проза, драма, поэтик әсәрләрнең әлегә кадәр булмавы җәмәгатьчелектә, укучыда, тамашачыда, сәнгать сөючедә бу хәлгә урынлы ризасызлык тудыра. 2005 елда Айдар Юзеевның Ш.Мәрҗанигә багышланган 350 данәдә генә басылган 112 битлек "Звезда по имени Марджани" исемле документаль-биографик повесте "Гасыр" нәшриятында "Гасырлар авазы - Эхо веков" журналына кушымта буларак дөнья күрде. Аны, һичшиксез, якын араларда татар теленә тәрҗемә итеп, зуррак тиражда бастырып, укучыларга, бигрәк тә мәктәп укучысына тәкъдим итү мәслихәт.

***(Ахыры 4 нче биттә.)***

# Зирәклек патшалыгы

***(Дәвамы. Башы 1 нче биттә.)***

Ислам дине болгар фәне һәм мәдәниятенә тизләтелгән үсеш ясарга мөмкинлек бирә. XI гасыр ахыры - XII гасырның беренче яртысында Болгар иленең башкаласы Бөек Шәһәрдә (Биләрдә) танылган галим, тарихчы, баш казый Йакуб ибне Ногман яшәгән. Ул - мәшһүр "Болгар тарихы" китабының авторы. Бу китапта болгар патшасының үз гаиләсе белән ислам дине кабул итүе турында да әйтелә. 1135 елда ерак Испаниядән килгән гарәп сәяхәтчесе Әбу Хәмид әл-Гарнати (әл-Андалуси) шул тарихи әсәр белән тирәнтен танышып чыга һәм аңа зур бәя бирә. Биләрдә X йөздә үк салынган зур мәчет була (аның калдыкларын безнең көннәрдә дә күрергә мөмкин). Мәчет каршында бөтен ислам дөньясында атаклы югары уку йорты саналган мәдрәсә эшләп килгән. Бу данлыклы гыйлем учагында төрле Шәрык илләреннән килгән шәкертләр белем алган. Мондагы гыйлем байлыгына исе киткән Әл-Андалуси ханнан олы улын Биләр мәдрәсәсендә белем алу өчен калдыруларын үтенә. Әлеге университетта Исламга, тарихка, фәлсәфәгә, географиягә, әдәбиятка, астрономиягә, мантыйкка кагылышлы фәннәрне тирәнтен үзләштергәннәр.

XVII гасырда яшәгән төрек библиографы Хаҗи Хәлиф үзенең бер әсәрендә Болгар илендә дөньяви фәннәрнең үсешенә бәйле кызыклы мәгълүматлар китерә. Ул бер болгар астрономы турында хәбәр итә. X гасырда әлеге галим Болгардан төньякта (меңнән артык чакрым ераклыкта) астрономик күзәтүләр оештыра, махсус экспедиция Кар диңгезе (Карское море) ярында үзенең фәнни-тикшеренү эшләрен алып бара.

XIV гасырда иҗат иткән әдипләрнең әсәрләрендә урын алган Галәм турындагы фикерләр үзләреннән алда яшәгән болгар галимнәренең фикерләренә нигезләнүендә шик юк. Мәсәлән, XIV йөз шагыйре Котб үзенең 1342 елда язылган "Хөсрәү вә Ширин" әсәрендә Галәм (Космос) турында болай яза: "Һәр йолдыз - аерым Дөнья, алар арасында зур ераклык бар һәм алар Галәмдә мәңге хәрәкәттә яши". 1394 елда Алтын Урда чоры шагыйре Сәиф Сараи болгар астрономы Масуд йогынтысы сәбәпле үзенең "Сөһәил вә Гөлдерсен" әсәрендә тирән, кыю фәнни фикерен җиткерә:

- Әйләнде егет бу яшь кыз тирәли.
Җир әйләнгән кебек кояш тирәли.

Игътибар иттегезме? 1394 нче ел! Николай Коперниктан 150 ел, Джордано Брунодан 200 ел алда безнең ата-бабалар Җирнең Кояш тирәли әйләнүен, гадәти итеп карап, шигырьгә керткәннәр. Моның өчен аларны беркем дә яндырмаган, эзәрлекләмәгән. Акыл һәм Гыйлем тантана иткән җирдә генә шулай була ала!

Болгарстанда медицина (тыйб) фәне дә бик нык алга киткән була. 1220-1221 нче елларда ике бертуган табиблар - Хәсән һәм Таҗетдин ибне Юныс әл-Болгари гарәп медикларының үтенече буенча "Әт-Тирйәк әл-Кәбир" ("Агулануга каршы даруларны ничек әзерләргә?") дигән трактат яза. Бөтен Шәрык дөньясында атаклы әлеге хезмәт безнең көннәргә кадәр килеп җиткән. Ул хәзерге вакытта Иран башкаласы Тәһранның фәнни китапханәсендә саклана. 1996 елда рәсми сәфәре вакытында тарихи кыйммәткә ия әсәрнең ксерокопиясе тантаналы рәвештә Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиевкә тапшырылды һәм ул аны Казан университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсенә бүләк итте.

Тагын бер болгар табибын искә алып үтәсе килә. Ул XI гасырда яшәгән. Сүз Хуҗа Әхмәд Болгари турында бара. Аның даны бөтен Ислам дөньясына тарала. Табиб Болгарстаннан Әфган иленә күчеп китә һәм Газни шәһәрендә авырган кешеләрне дәвалый башлый. Күпләрне ул аякка бастыра. Аның турында шигырьләр иҗат ителә, ә исеме риваятьләргә керә. Аның хөрмәтенә 1971 елда ак мәрмәрдән дөрбә (мавзолей) куела.

Ләкин Хуҗа Әхмәд Болгари табиб кына булып калмый. Ул үзенең фәлсәфи һәм тарихи әсәрләре аша бар Ислам дөньясына таныла. Элек XI гасырда язылган "Тарихател Болгария", "Фәнандел Болгария", "Җәмигыль Болгария" дигән әсәрләре бик киң таралган була. Хуҗа Әхмәд Болгарины Мәхмүд Газнәви солтан үз янына чакырта һәм аңа укытучы, киңәшче вазифалары йөкләтелә. Мөселман сәяхәтчеләре, галимнәр Болгар илен "Зирәклек патшалыгы", "Шәрыкның алтын тәхете" дип тикмәгә генә атамаганнардыр, күрәсең.

Мәгълүм ки, болгар мәдрәсәләрендә әдәбиятны тирәнтен өйрәткәннәр. Әдәби әсәрләрдән бигрәк тә болгар шагыйре Кол Галинең 1212-1233 елларда иҗат ителгән "Кыйссаи Йосыф" поэмасы аерылып тора. Нәрсәсе белән? Бу даһи әсәрдә сүз сугыш турында бармый. Ә борынгы һәм урта гасырлардагы Европа һәм рус әдәбиятында сугыш төп тема булып тора. "Кыйссаи Йосыф" поэмасында гаделлелек, кешелеклелек, намуслылык, юмартлык, инсафлык, татулык, тынычлык кебек сыйфатларга мәдхия укыла. Табигый ки, безнең болгар-татар халкына бу әсәр бик тә кадерле.

***(Ахыры 4 нче биттә.)***

# Илһам хәзрәт кайтарган илһам

**"Киңәшем шул: тәнең белән җаныңны тәңгәллектә тотасың, башкаларга акыллы киңәшләр бирәсең, гомер буе кирәкле кеше булып каласың килсә, дини гыйлем үзләштер!" - диде хәзрәт.**



Кая бара бу дөнья?! Никтер җаным үзенә урын табалмый бәргәләнә соңгы вакытта. Бер эшемнән дә үзем теләгән нәтиҗә ала алмыйм. Кая карасам да, проблема. Сораулар миллион. Җавап юк. Уйлап утырырга, нидер хәл итәргә вакыт та юк... Мөлдерәмә тулы күңелемне көннәрдән бер көнне эш урыныма кергән Илһам хәзрәткә бушаттым.

- Әнә теге чебенгә кара әле, - диде ул. Тәрәзә пыяласында иртәннән бирле, эчне пошырып, бармак башы кадәр бер чебен безелди иде. - Аның да зәңгәр күкләргә, чәчәкле болыннарга чыгып очасы килә. Тик, мескен, башын бәрә-бәрә, безелдәп, шунда тәрәзә төбенә төшеп үләсен белми. Соң, башы белән уйлап караса, әнә бит ишек шыр ачык, ник шуннан очып чыгып китми ул? Гомер буе бер үк эшне эшләп утырганнан, нәтиҗә шул ук була, тормышыңа үзгәреш кертергә, хикмәт белән эш итәргә өйрәнергә вакыт, - диде хәзрәт.

- Ә ничек итеп? - дип сораганымны сизми дә калдым.

- Кытайга барып булса да, гыйлем ал! - ди хәдис.

- Гыйлememне болай да кая куярга белгән юк. Мәгълүматтан баш әйләнә, "Горе от ума" башланды бугай инде.

- Кара әле, тәрәзә артындагы теге агачка. Аның кәүсәсе, ботаклары, ябалдашлары бар, әйеме? Адәм баласы өчен төп кәүсә - дини гыйлем. Бишектән ләхеткәчә, ягъни туганнан алып, яшәү дәверендә, үлгәндә һәм ахирәт дөньясына баргач та кирәк. Ә ботаклар, ябалдашлар - бу дөньяда корып, кирәге бетәргә мөмкин белемнәр. Мәсәлән, пенсиягә чыккач, һөнәреңнең кирәге калмый. Ә дини гыйлем - мәңгелек. XXI гасыр - мәгълүмат һәм рух гасыры. Велосипед уйлап чыгарып, үзем-үзем дип, абына-сөртенә, ялгыш арты ялгыш ясап вакыт уздырганчы, тормышта уңышка ирешкән кеше тап, аның уңай тәҗрибәсен өйрән, үрнәк ал. Үзең үзгәрергә теләсәң, өйрәтүчеләр табылыр.

Хәзрәт китте. Олы сабак биреп, күңел күземнең ярасын ачып китте. Аллаһы Тәгаләнең кодрәте, хикмәте белән мин аны и-ш-е-т-т-е-е-ем!!! Тормышымда тамырдан борылыш шул мизгелдән башланды да инде. Миннегалиевлар гаиләсе белән тыгыз аралаша башладым. Илһам хәзрәтнең хатыны Әлфирә абыстай - үзе бер могҗиза. Аларның яшәү рәвешләрен күреп гаҗәпкә калам: биш бала үстерәләр, "Хәләл" кибете тоталар, халыкка мәгърифәт, дини гыйлем бирү юлында үзләрен аямыйлар. Журналист буларак күзәтәм: мөхтәсиб Илһам хәзрәт җитәкчелегендә киң колачлы дини эш гөрләп бара бит безнең районда. Ә ул һаман укый. РИУга керде. Мин дә Мамадышыбыздагы мәдрәсәбезнең III курсында. Аллаһы Тәгалә тарафыннан Җир йөзенә җибәрелгән иң соңгы изге китап, адәм балаларына яшәү инструкциясе - Коръәнне кулыма алдым. Шәригать кануннарын ныклап өйрәнәм, алган гыйлемнәрем буенча игелекле гамәлләр генә кылырга омтылам. Мине хак, туры юлга бастырган, кыйбламны үз вакытында дөресләп җибәргән, яшәү мәгънәсен янәдән аңлаткан, иҗатка илһамымны кире кайтарган Мамадышның хикмәтле, иң ихлас кешеләре, мөэмин мөселманнар Илһам хәзрәт белән Әлфирә абыстай кебек рухи остазлар бүләк иткән Аллаһы Тәгаләмә мең рәхмәтләр укыйм. Кешеләрнең күңелләрендә өмет, ышану һәм мәхәббәт бервакытта да сүнмәсен-сүрелмәсен! Барчабыз да үзебезнең рухи остазларыбызны тизрәк тапсак иде дигән теләктә калам.

***Алсу ДИЯР. Мамадыш районы***

# Ш.МӘРҖАНИ ОБРАЗЫ ӘДӘБИЯТТА ҺӘМ СӘНГАТЬТӘ

*(Ахыры. Башы 3 нче биттә.)*

Ш.Мәрҗани образын нәкышче, сынчы, график буларак иҗат итүдә Татарстан сәнгать осталары берникадәр файдалы эш башкарды: Б.Урманче, А.Головачев һәм В.Демченко кебек сынчылар галимнең бюстларын, Бакый Урманче, Канәфи Нәфыйков, Эрот Зарипов, Виктор Фёдоров, Альфред Әбдрәшитов кебек рәссамнар мәгърур шәхеснең портретларын ясады. Татарстанның һәм Үзбәкстанның халык рәссамы Чыңгыз Әхмәров "Шиһабетдин Мәрҗанинең шәкерт чагы", "Мәрҗани һәм Сәмәрканд галиме Сәет Абдулла", Рәшит Гыйләҗев "Мәрҗани мәчете" исемле рәсемнәрен иҗат итте. Режиссёр Салават Юзеев "Мәрҗани коесы" исемле документаль фильмын тудырды (2000).

Аерым урамнар, ТР Фәннәр академиясенең Тарих институты, Казандагы мәчет, башкалабыздагы 2 нче татар гимназиясе, Әтнә районының Комыргуҗа урта мәктәбе Ш.Мәрҗани исемен йөртә. Бу уку йортларында данлы галимнең тормыш юлын, гыйльми-педагогик эшчәнлеген шактый киң яктыртучы музейлар эшли. Татарстан Фәннәр академиясе 1993 елдан иң яхшы фәнни хезмәтләр иҗат итүче галимнәрне тәрбияләү өчен Ш.Мәрҗани исемендәге бүләкне булдырган иде. Аның беренче лауреатлары Яхъя Абдуллин, Мөнир Йосыпов, Нурмөхәммәт Хисамов, Гариф Ахунов, Айдар Ногманов булды.

Татар халкы мәшһүр улын тирән хөрмәт итә. Тик аның шәхесен пропагандалау, бай тарихи мирасын халыкка җиткерү, хезмәтләрен гади укучы аңлый алырлык хәлгә китерү - тәрҗемә итеп бастыру өлкәсендә дә җитди эш алып бару сорала әле. Могтәбәр затка багышланган һәйкәлнең соңгы дистә еллар буенча үз исеме белән аталучы Казан урамына килеп баса яки утыра алмавы (галимнең 180 еллыгын билгеләп үткәндә матбугат, радио, телевидение бу хакта кат-кат хәбәр итсә дә, бик кызганыч, бу вәгъдә үтәлмичә кала), бөек галимгә багышланган яхшы сыйфатлы нәфис фильмның экранда, спектакльнең республикабыз театрлары сәхнәсендә күрсәтелмәве, дәүләт музеенда тирән эчтәлекле нәфис рәсемнәрнең хәзергәчә җитәрлек булмавы күңелне борчый.

Мәшһүр галимнең 195, 200 еллыкларына да ерак калмый. Данлы затның гыйбрәтле тормыш юлын, төрки халыкларның, шул исәптән туган татар халкының рухи үсешенә керткән гыйльми эшчәнлеген пропагандалауга игътибар, хәстәрлек тагын да арттырыла төшсә, бөек шәхескә багышланган зур күләмле матур әдәбият, сәнгать әсәрләре иҗат ителсә, изге гамәл башкарылыр, киң масса укучылар, тамашачыларның урынлы теләге, өмете билгеле дәрәҗәдә тормышка ашар иде.

***Фәнис ИСЛАМОВ, педагогика фәннәре кандидаты***
***Азат СӘЙФЕТДИНОВ фотосы***

# Зирәклек патшалыгы

*(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)*

Казан ханлыгы чорында да безнең халкыбыз үзенең югары дәрәҗәдәге рухи мәдәниятен дәвам иттерә һәм аны яңадан-яңа баскычларга күтәрә. Казанда, Болгар әл-Җәдидтә (Яңа Болгарда) һәм башка шәһәр-авылларда мәктәп-мәдрәсәләр гөрләп торган.

1236 елда монгол-татар һөҗүменнән соң, Болгар иленең башкаласы Биләрдә барлык мәһабәт биналар җимерелә, аның белән беррәттән атаклы мәдрәсәләр дә көлгә әйләнә. Бу уку йортларында формалашкан мәгариф системасын Алтын Урда чорында эшләп килгән шәһри Болгар, аннары Казандагы мәшһүр Кол Шәриф мәдрәсәләре дәвам иттерә. Казан ханлыгы чорында яшәгән бөек шагыйрь, фәлсәфәче Мөхәммәдьяр үзенең "Төхфәи мәрдан" (1539) һәм "Нуры содур" (1542) әсәрләрендә Томас Мор, Колюччо Салютати, Франческо Петрарка, Томмазо Кампанелла, Феодосий Косой, Кол Гали, Ганҗәви Низами, Галишер Нәвои, Фирдәүси, Шота Руставели һәм башка авторлар кебек утопик дәүләтләр турында яза, халкының киләчәге турында кайгырта. Ул изүләрдән азат булган һәм төрле динне тоткан тигез хокуклы кешеләр җәмгыяте турында хыяллана.

Мөхәммәдьяр, Сөембикә ханбикәнең карарын үтәп, дөньядагы рухи хәзинәләрне бай китапханәгә туплый башлый. Бу китапханәдә укымышлы кешеләргә, белем эстәүче талантлы яшь шәкертләргә ишекләр гел ачык була. Алар бирелә фәлсәфә, тарих, медицина, астрономия һәм әдәбият буенча дан казанган әсәрләр белән таныша алганнар. Кызганыч, әлеге данлыклы китапханәнең язмышы бүгенге көнгәчә билгесез һәм серле булып кала бирә.

Кызганыч, без тарихыбызны тулысынча белмибез. Әгәр дә аны өйрәнсәк, белсәк, аның егерме миллионлы болгар-татар халкының кешелек цивилизациясе тарихында нинди урын тотканлыгын яхшырак аңлар идек. Һәр кеше үз халкының тарихын өйрәнергә тиеш. Без Франция, Англия, Германия, Италия, Япония, Америка, Греция, Испания тарихлары белән кызыксынабыз, ә үзебезнең Болгар һәм Казан ханлыклары тарихын белергә омтылмыйбыз. Бу гафу ителмәслек хәл!

Ә бит безнең тарихыбыз белән бабаларыбыз да, Рәсәйдән, ерак илләрдән килгән укымышлы кешеләр дә кызыксынып килгәннәр.

Мәгълүм булганча, Пётр I, Болгардагы Кече манарага менеп, борынгы архитектура корылмаларын карагач, соклануын яшерә алмый һәм шәһәрнең калган өлешен саклау турында карар кабул итә.

Сүз уңаенда әйтеп үтим, минем бабам - күренекле җәмәгать эшлеклесе, тәрҗемәче Йосыф Ижбулатов - Пётр I боерыгы буенча (ахун Сөнчәләй белән бергәлектә) 50 болгар кабер ташының язуларын күчереп, аны рус теленә тәрҗемә итә һәм Петербург Фәннәр академиясенә тапшыра. Бу кыйммәтле болгар язулары шул рәвешле тарихка кереп кала. Й.Ижбулатов фарсы телендә язылган "Дербентнамә" поэмасын рус теленә тәрҗемә итеп, Пётр Беренчегә бүләк итә. Бу мәгълүматларны "Татар Энциклопедиясе сүзлеге"ннән дә табарга мөмкин.

Кызганыч, изге болгар кабер ташлары, Пётр I вафат булганнан соң, рус чиркәве төзелгәндә аның нигезенә салына, шактые туза, ватылып юкка чыга. Идел буе мөселманнары беркайчан да мондый вәхшилеккә бармаган, христианнарның кабер ташларын мәчет нигезенә салмаган. Без башка диннәргә зур ихтирам, хөрмәт белән карадык һәм караячакбыз.

Бүгенге көндә илебездә мөселманнар башка дин вәкилләре белән татулыкта яши. Безнең Татарстаныбызда да тынычлык. Республикабыз башка төбәкләргә күп яктан үрнәк булып тора: әйтик, 1999 елны Татарстан башкаласында Халыклар дуслыгы йорты ачылды, шуннан соң озак та үтми, Дөнья мәдәнияте институты барлыкка килде. Казан Кремлендәге Кол Шәриф мәчете, Сөембикә манарасы белән янәшә урнашкан Благовещение Соборы ислам һәм христиан диннәренең бердәмлеген символлаштыра. Ә Казан Кремле үзе ЮНЕСКО исемлегенә кертелгән.

Илебезнең төрле тарихи төбәкләрендә яшәп, болгар-татарлар бер-берсе белән кан-кардәшлекне тәшкил итә. Шуның өчен Россия, болгар-татар варисларының гына түгел, башка халыкларның да уртак йорты булып тора.

**Мидхәт ИЖБУЛАТОВ, Ислам дине кабул итүнең меңьеллыгы исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсе мөгаллиме**

## Казанда намаз вакытлары

| Көн исеме | Дата | Иртәнге намаз | Кояш чыгу | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Шимбә | 7.03.12 | 4:28 | 5:58 | 13:02 | 17:24 | 19:35 | 21:05 |
| Якшәмбе | 8.04.12 | 4:26 | 5:56 | 13:02 | 17:25 | 19:37 | 21:07 |
| Дүшәмбе | 9.04.12 | 4:23 | 5:53 | 13:02 | 17:27 | 19:39 | 21:09 |
| Сишәмбе | 10.04.12 | 4:21 | 5:51 | 13:02 | 17:28 | 19:41 | 21:11 |
| Чәршәмбе | 11.04.12 | 4:18 | 5:48 | 13:02 | 17:29 | 19:43 | 21:13 |
| Пәнҗешәмбе | 12.04.12 | 4:16 | 5:46 | 13:02 | 17:31 | 19:45 | 21:15 |
| Җомга | 13.04.12 | 4:13 | 5:43 | 13:02 | 17:32 | 19:47 | 21:17 |
| Шимбә | 14.04.12 | 4:11 | 5:41 | 13:02 | 17:33 | 19:49 | 21:19 |

**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. №14 (131) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** Е-529.
**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
***График буенча бу санга 5 апрель көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.
Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан саклаңыгыз!**